ГЛАВА
ЛЕБЯЖИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЕБЯЖЬЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** с. Лебяжье **КАРАР**

**03.11.2021е.** **№ 4**

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлегенең Сакон авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56, 25.1 маддәсендәге 1 өлешенең 4, 4.1 һәм 4.3 пунктлары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге Уставының 23 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге Советының 2019 елның 08 октябрендәге 136 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебяжье авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең 2.5 пункты нигезендә

**карар бирәм:**

1. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебяжье авыл җирлегенең Сакон авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 19 ноябренә 11:00 сәгатькә билгеләргә.

Җыенны үткәрү урыны итеп түбәндәге адрес буенча урнашкан клуб бинасын билгеләргә: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Сакон ав., Үзәк ур., 39 й.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Лебяжье авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
- техниканы - тракторны карап тоту;
- урамнарны яктырту;
- балалар мәйданчыгын киртәләү;
- җирләү урыннарын төзекләндерү;
- су белән тәэмин итү челтәрләрен реконструкцияләү.

ӘЙЕ   ЮК».

4. Әлеге карарны Лебяжье авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Лебяжье авыл җирлеге башлыгы** **Д.Ә. Гыйләҗев**